# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**(III чакырылыш)**

егерме җиденче утырыш

# КАРАРЫ

28 март 2019 ел **№ 173** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 10 октябрендәге 64 санлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маендагы 26 санлы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында»гы законның 16 статьясына, Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маендагы 26 санлы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында»гы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 сентябрендәге 798 санлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 10 октябрендәге 64 санлы карары белән (район Советының 12. 04. 2012 елгы №100, 24. 09. 2012 елгы №122, 27. 10. 2015 елгы №13, 19. 07. 2017 елгы №91, 13. 11. 2017 елгы №109, 24. 08. 2018 елгы № , 21. 11. 2018 елгы №151 карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составын яңа редакциядә бирергә һәм түбәндәге составта расларга:

«Комиссия рәисе:

1. Нурмөхәммәтов А.А. – район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Комиссия рәисе урынбасары:

2. Карпова Н.В. – Теләче муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе начальнигы.

Комиссиянең җаваплы секретаре:

3. Хәнәфиева М.Ф. – Теләче муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең баш белгече.

Комиссия әгъзалары:

4. Тимерханов А.А. – Теләче районы буенча Россия ЭЭМ бүлекчәсе начальнигы урынбасары полиция подполковнигы (килешү буенча);

5. Галимҗанов А.М. – Теләче муниципаль районы мәшгульлек үзәге дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча);

6. Исламова Н.Р. – Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы баш белгече;

7. Емельянов Ю. И. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы;

8. Исмәгыйлева Р.М. - Теләче муниципаль районы «Теләче район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең педиатрия бүлеге мөдире (килешү буенча);

9. Гыйниятуллин И.С. – район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы;

10. Кашапов Б.Р. - «Теләче район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча урынбасары, поликлиника мөдире (килешү буенча);

11. Низамова Л.М. – Теләче муниципаль районында «Родник» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү бүлекчәсе мөдире (килешү буенча);

12. Нәбиуллина А.Р. – район Башкарма комитеты мәдәният бүлегенең әйдәп баручы белгече;

13. Хаҗипова С.Н. – мәгариф бүлеге педагог-психологы, ТР балалар хокуклары буенча вәкаләтлесенең Теләче муниципаль районы буенча җәмәгать ярдәмчесе;

14. Хафизов Р. М. – Теләче районы буенча ТР Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе инспекторы (килешү буенча);

15. Шакирова Г.Р. - Теләче муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе начальнигының тәрбия эше буенча урынбасары.

2. Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 10 октябрендәге 64 санлы карары (район Советының 2018 елның 21 ноябрендәге 151 санлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турындагы Нигезләмәне көчен югалткан дип табарга.

Теләче муниципаль<br>районы Башлыгы И.Ф. Зарипов